ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЙБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422726, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Айбаш авылы, Үзәк ур., 1А

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЙБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422726, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Айбаш, ул. Центральная, 1А

тел./факс 8(84365) 60-7-23, e-mail: Ayb.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**29 апрель 2025 ел** **№ 2**

**«Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре, баш бухгалтер һәм бухгалтерларның хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитеты 11.11.2019 № 11 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының 03.04.2025 елның 03-12/2212 номерлы «Шәһәр һәм авыл җирлекләре үзәкләштерелгән бухгалтерлыклары һәм бухгалтерлары җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт хакы түләү турында» хаты нигезендә һәм Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль берәмлеге учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү системасын камилләштерү максатларында

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 нчы елның 11 нче ноябрендәге 11 нче номерлы «Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре, баш бухгалтер һәм бухгалтерларның хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында» Башкарма комитет карары белән расланган үзәкләштерелгән бухгалтерия бухгалтерларының һәм баш бухгалтерларның айлык хезмәт хакы күләмен 2025 нче елның 1 нче маеннан арттырырга.

2. Айбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 11 ноябрендәге «Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары, Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының, хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында" (30.09.2020 № 6, 26.10.2020 № 7, 02.12.2022 № 5, 23.03.2023 № 2, 24.06.2024 № 3, 25.11.2024 № 7 карарлары редакциясендә) карары белән расланган «Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге баш бухгалтеры һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында» нигезләмәнең 3 нче пунктындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары |
|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше |
| Баш бухгалтер (1 ст.) | 28 200 |

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында " Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар 2025 нче елның 1 нче маеннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
Айбаш авыл җирлеге Р.Р. Сафиуллин